| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ПЕЧИЩИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ПЕЧИЩИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

24.03.2023 с. Печищи № 7

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Печищи авыл җирлеге торак пунктларын төзекләндерү һәм санитар-экологик чистарту икеайлыгы үткәрү турында

Югары Ослан муниципаль районының Печищи авыл җирлеге торак пунктларын төзекләндерү һәм санитар чистарту эшләрен оештыру һәм халыкның экологик һәм санитар-эпидемиологик иминлегенә җавап бирә торган халәткә китерү өчен,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2023 елның 1 апреленнән 31 маена кадәр Печищи авыл җирлегенең торак пунктлары территорияләрен төзекләндерү һәм санитар-экологик чистарту буенча ике айлык игълан итәргә (алга таба - ике айлык).
2. 2023 елга Печищи авыл җирлеген төзекләндерү комитеты составын расларга (1 нче кушымта).
3. Печищи авыл җирлеге территориясендә 2023 елның 01 апреленнән 31 маена кадәрге чорда төзекләндерү чаралары планын расларга. (2-нче кушымта).
4. Печищи авыл җирлеге территориясендә урнашкан предприятие, оешма һәм учреждениеләр җитәкчеләренә, милек рәвешләренә бәйсез рәвештә, үзләренең якын территорияләрен санитар чистарту эшен оештырырга, каты көнкүреш калдыкларын полигонга һәм чүплекләргә чыгару өчен йөк автотранспорты бүлеп бирергә тәкъдим итәргә. Урыннарда агач һәм куаклар утырту, биналарның фасадларын, балалар мәйданчыкларын ремонтлау эшләрен оештырырга.
5. Авыл җирлеге территориясендә күчемсез милеккә ия булган гражданнарга нинди хокукка ия булуларына карамастан, үзләренең йорт яны территорияләрен санитар чистарту буенча эш алып баруны тәкъдим итәргә.
6. Әлеге карарны Печищи авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.
7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Печищи авыл җирлеге башлыгы Е.В. Рахматуллина

Печищи авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2023 елның 24 мартыннан
7 номерлы карарына
1нче кушымта

Печищи авыл җирлеген төзекләндерү комитеты составы

1. Рахматуллина Екатерина Владимировна - Югары Ослан муниципаль районының Печищи авыл җирлеге башлыгы

2. Алифанов Вячеслав Александрович - 5 нче Печищи сайлау округы депутаты

3. Волкова Любовь Дмитриевна - Югары Ослан муниципаль районының Печищи авыл җирлеге Башкарма комитеты секретаре

4. Боева Ольга Владимировна - 2 нче Печищи сайлау округы депутаты

5. Полякова Галина Васильевна - Печищи авыл мәдәният йорты мөдире, 1 нче номерлы Печищи сайлау округы депутаты.

Печищи авыл җирлеге башлыгы Е.В. Рахматуллина

Печищи авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2023 елның 24 мартыннан
7 номерлы карарына
2нче кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Печищи авыл җирлеге территориясендә ике айлык кысаларында санитар-экологик хәлне яхшыртуга юнәлтелгән төзекләндерү һәм санитар чистарту буенча чаралар планы

| № | Чараның атамасы | Үткәрү датасы | Җаваплы оешмалар, затлар |
|---|---|---|---|
| 1. | Авыл җирлеге территориясендә урнашкан чүплекләрне бетерү буенча эшләрне оештыру һәм үткәрү | Апрель ай | Печищи авыл җирлегенең депутат корпусы, участковый, фельдшер |
| 2. | Торак пунктлар территориясен чүп-чардан җыештыру | Апрель ай | Печищи авыл җирлеге Башкарма комитеты, депутат корпусы |
| 3. | Шәхси торак йортларның йорт яны территориясен җыештыру | Апрель ай | Печищи авыл җирлеге Башкарма комитеты, участковый, халык |
| 4. | Авыл җирлеге территориясендә торак пунктлар эчендәге баганаларны буяу | Май ае | Печищеи авыл җирлеге Башкарма комитеты, «Печищи төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе, «Печищи балалар бакчасы» МБДОУ |
| 5. | Авыл җирлеге территориясендә урнашкан учреждениеләрнең, предприятиеләрнең фасадларын ремонтлау | Май айлары | Учреждениеләр, предприятиеләр җитәкчеләре |
| 6. | Авыл җирлеге территориясендә урнашкан зиратларны төзекләндерү (коймаларны ремонтлау, коймаларны буяу, чүп-чарны чыгару) | Май ае | Печищи авыл җирлеге Башкарма комитеты, халык |
| 7. | Печищи авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасы территориясен төзекләндерү | Май ае | Печищи авыл җирлеге Башкарма комитеты |
| 8. | Печищи авыл җирлегенең торак пунктларында яшел үсентеләр утырту. | Май ае | Печищи авыл җирлеге Башкарма комитеты, “Печищи төп гомуми белем |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | бирү мәктәбе” муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе |
| 9. | «Гремячка» су җыю җайланмасын төзекләндерү | Май ае | Печищи авыл җирлеге Башкарма комитеты, «Печищи» МУП |
| 10. | Сәүдә мәйданчыкларында һәм җәмәгать туклануы объектларында санитар-гигиеник таләпләрне үтәү һәм төзекләндерү буенча эшләр башкару | Даими | Сәүдә нокталары һәм җәмәгать туклануы пунктлары хуҗалары |
| | | | |

Печищи авыл җирлеге башлыгы Е.В. Рахматуллина